**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_____________ 31.05.2024 № ПР-97 № ______

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТАТАР-СУЫКСУЫ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕН ҮЗГӘРТЕП КОРУ ТУРЫНДА**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге, 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктына таянып,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының 2024 елның 28 маендагы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссиясенең 30 нчы бәяләмәсе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының 2024 елның 15 апрелендә уздырылган Татар Суыксуы авылы гражданнары җыелышы беркетмәсе нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш районының «Татар-Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Татар-Суыксуы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә 2024 елның 31 июленнән үзгәртеп корырга.

2. «Татар-Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Ф.Ф.Газизовка:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Татар-Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәрешләр проекты әзерләргә;

-хезмәт законнарына ярашлы рәвештә, үзгәртеп корыла торган белем бирү учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;

-Татарстан Республикасы Актаныш районының «Татар-Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен үзгәртеп коруны башкарырга.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.Р.Сираева